**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.11.2021 № 996

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020елның 9 июнендәге 633 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 П., «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешенең 1 п. һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында "Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта

гомуми белем бирүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020елның 9 июлендәге 633номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

6.7 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«6.7. Белем алучы яисә балигъ булмаган укучы ата-аналар (законлы вәкилләр) инициативасы буенча белем бирү мөнәсәбәтләрен вакытыннан алда туктату «әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса» белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма алдында күрсәтелгән белем алучының нинди дә булса өстәмә, шул исәптән матди йөкләмәләре барлыкка килүгә китерми.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е. В. Сороковнинага йөкләргә.

Җитәкчесе Р. М. Заһидуллин